ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.06.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1242**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 12.04.2021 ел, №779 карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 12.04.20021 ел, №779 карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә җибәрелгән техник хаталарны төзәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 12.04.20021 ел, №779 карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. V бүлекнең 7.12. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«7.12. Авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче физик культура хезмәткәрләренә, педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләренә, урта медицина һәм фармацевтика персоналының, табибларның һәм провизорларның һөнәри квалификация төркемнәренә керүче медицина хезмәткәрләренә, мәдәният, сәнгать һәм урта, әйдәп баручы звено һәм җитәкче составтагы мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

биредә:

$B_{sm}$ – авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү;

$D_{sm}$ – авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү күләме, 1 388,5 сумга тигез күләм;

$S$ – яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләре били торган ставкаларның фактик саны.;

1.2.VIII бүлекнең 5 пунктында беренче абзацында «билгеләргә мөмкин » сүзләрен «билгели» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 VIII бүлекнең 6 пунктында «билгели  ала» сүзләрен «билгели» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 VIII бүлекнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесе, җитәкче урынбасарлары, баш хисапчы эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенең критерийлары һәм аларның үлчәү коэффициентлары локаль актлар белән раслана».

2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль норматив актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев